**/Укучылар иҗаты/**



### Авылым язы

Март ае кояшка бай икәнен барыбыз да беләбез инде. Кузен кысып кына хәйлә белән безне йомшак җылысында коендыра. Нурлары өстеңә килеп төшүгә, кышкы киемнәреңне салырга боерган кебек була. Кояш шулай тыныч кына үз максатларына ирешә башлый.

Быелгы бер дә бетмәс тоелган карны, Такташча әйтсәк, март аеның нечкә билле җиле җиргә сузылып ятып ашап та бетерде. Күз ачып йомганчы кар астыннан яшел чирәмнәр борын төртте. Шул арада Чирмешән елгасы калын бозыннан арынып өчен, тирән итеп сулыш алды да, бозларын ватып, әрәмә тугаена таратты. Бер мизгел эчендә авылыбыз диңгез уртасында калгандай булды.

Бу көнне иртән үк авыл урамнары җанланган иде. Барча авылдашлар бергәләшеп Чирмешән елгасының матурлыгына, ташуына сокланып йөрде. Кечкенә генә елгаларның да Чирмешәнгә кушылырга ашыгып аккан тавышлары авылны филармония залына әйләндерде. Чөнки урман сулары үзләренең көче аз булуын аңлап, төрле кечкенә юллар аша, зур елгага кушылырга омтылдылар. Ялгызлыктан качып, бергәләшеп, кочаклашып зуррак елгаларга кушылырга ашкындылар. Акчарлаклар әрәмәлекнең ачык калган урыннарында азык булуына шатланып хор белән җырладылар. Шул арада күктән кыр казлары, үрдәкләре тавышлары яңгырады. Бер-бер артлы тезелеп кайткан кошлар җыры авылның матурлыгына тагын бер кат ышандырды. Табигатьнең мондый гүзәллеген тагын кайдан күрәсең? Бу бит бары тик язгы мәлнең бер мизгеле генә әле. Ә тиздән, бик тиздән, авылым минем яшел бишеккә әйләнер. Сары түзганаклар белән бизәлгән яшеллек матурлык өстенә матурлык өстәр.

**Зәйнәп Нурматова, Хсыйныф укучысы**

### Кызыклы грамматика

1. Кайсы бодайдан кортлар бал ала?
2. Нинди ике нота бакчада үсә?
3. Кайсы кошның исеменнән бер иҗекне алсаң, кар өеме килеп чыга?
4. Кайсы ике нотага бер үк авазны кушсаң, ике алмашлык килеп чыга?
   Шул ук авазны өченче нотага кушсаң, елга исеме чыга?
5. Кайсы нотага бер аваз кушсаң, шәһәр исеме барлыкка килә?
6. Нинди оякда бервакытта да йомырка булмый?
7. Нинди бугаз сулый алмый?
8. Нинди дәүләтне башка киеп йөриләр?
9. Җир шарының кайсы урынына төньяктан гына барып була?
10. Кайсы җир бервакытта да искерми?

**/Күңелле тәнәфес/**

### Ребуста нинди мәкаль яшерелгән?



**/Котлыйбыз!/**



Март аенда дөньяга килгән дусларыбыздан II сыйныф укучысы **Галиаскәрова Асияне**, IV сыйныфтан **Хусенов Диманы**, VI сыйныф укучысы **Ахсанова Мәдинәне**, VII сыйныф укучысы **Вәлиев Ибраһимны**, XI сыйныф егете **Морадимов Илсурны** туган көннәре белән котлыйбыз. Барысына да ныклы сәламәтлек, тырышып укуларын һәм тәртипле булуларын теләп калабыз.

Узган айда туган көне булып узган хөрмәтле укытучыбыз **Гафиятуллина Фәнүзә апаны** гомер бәйрәме белән котлап, исәнлек-саулык, гаилә иминлеге, эшендә зур уңышлар, барлык уй-теләкләреңнең чынга ашуын телибез!


Газетаны гамәлгә куючы – Түбән Майна урта мәктәбе
Мөхәррир – Фәнүзә Гафиятуллина
Редколлегия әгъзалары: Зәйнәп Нурматова, Самат Гафиятуллин, Кәүсәр Насыйрова, Ләйсән Закирова, Мәдинә Әхсәнова, Камил Тәхвәтуллин



# Мәктәп хәбәрчесе

Түбән Майна урта мәктәбе гәзите

Тел. 8 (84344) 4-38-46 sch1644maina@mail.ru

№3 (№54) март 2024 ел


**/Мөхәррир минбәре/**

### Буш вакытны бергәләп үткәрик

2024 гаилә елы

2024 нче ел Россиядә һәм Татарстанда **ГАИЛӘ ЕЛЫ** дип игълан ителде. Гаилә – дәүләтнең күзәнәге. Гаилә нык булса,дәүләттә нык була. Гаилә –кеше тормышында иң мөһим, иң кирәкле нәрсә. Гаилә ул – әти-әни, әби-бабай, абый-апа, эне-сеңел, туганнар. Мондый гаиләләр тулы гаилә дип санала. Анда һәр әгъза үзен бәхетле тоя, һәрьяклап тәрбия ала, аның сәләтләре ачыла,үсә.

Гаиләнең матур һәм тату булуы да якын туганнарның бер-берсенә ярдәмләшеп яшәве нәтиҗәсе. Уртак мәнфәгатьләр, бергәләп эшли торган эшләр булу – балаларга уңай йогынты ясый. Буш вакытларында әти-әниләр белән бергә булулары аларның рухи дөньяларын баета, моңарчы билгеле булмаган сыйфатларын, омтылыш-хисләрен белергә, аңларга ярдәм итә. Чөнки гаиләне олылар һәм балалар өчен бер-берсен яратырга өйрәнү мәктәбе диләр. Балаларның әти-әнисе, якын туганнары белән аралашуын мәктәптә яки җәмәгать оешмаларында уздырыла торган бернинди чара да алмаштыра алмый дип санаган педагог Сухомлинский.

Өлкәннәр тәҗрибәсен алып калуда да бергә эшләүнең, бергә өйрәнүнең әһәмияте искиткеч зур. Әти-әниләрнең әхлакый культура дәрәҗәсе, аларның тормыш планнары һәм омтылышлары, өлкәннәрнең аралашу тәҗрибәсе, гаилә традициясе – бер сүз белән әйткәндә, туган йорттагы бар халәт укучылар шәхесен формалаштыруда хәлиткеч әһәмияткә ия. Менә шундый гадәти, тормышчан аралашулар булса, балаларыбызның сөйләм теле дә, тирә-ягына карашы да уңай яктан формалаша. Ата-ана мәхәббәте баланы киң күңелле, ягымлы, ачык йөзле итә. Шушы мәхәббәт җылысы балада намуслылык, йомшак күңеллелек тәрбияли.

Күренә ки, буш вакытны бергә үткәрүнең әһәмиятле яклары күп. Бүгенге көннең иң зур проблемасы –туган телебезнең сафлыгын саклау икәнлеген күп тапкырлар кабатлап киләбез. Әгәр балалар үз гаиләләрендә ана телендә якыннары белән еш аралашсалар, укучыларыбызның сөйләме бай булыр иде. Туган телебездәге тормышчан, гадәти сөйләмдә яңгыраган төшенчәләрне тиз һәм үтемлерәк кабул итәрләр иде. Җанлы, турыдан-туры аралашуның азлыгы укучыларның өлгерешендә дә сизелә. Гаилә елында гына түгел, алдагы елларда да якыннарыбыз белән уйда, телдә һәм гамәлдә бердәм булып калсак иде!

***Фәнүзә Гафиятуллина, татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

### 8нче март – Халыкара хатын-кызлар көне



***Хөрмәтле хатын-кызларыбыз!***

***Язгы күркәм бәйрәмдә барыгыз-ны да котлап, ныклы сәламәтлек, матур тормыш, бәрәкәтле го-мер телибез. Нәни кызчыкларыбызга, сылу кызларыга гүзәллек, нәфислек үрнәге булуларын, хал-кыбызның горур, тыйнак, сабыр туташлары, апалары булып, кадерле хатын-кыз дәрәҗәсендә яшәвегезне телибез.***

*Хатын-кыз ул яз кебек,*
*Тормышны яңарта.*
*Хатын-кыз ул кояш кебек,*
*Өебезне җылыта.*

*Хатын-кызның күңеле кебек*
*Кояшның җылысы*
*Аның куллары әзерли*
*Из затлы ризыкны.*

*Хатын-кызның кулы назлы,*
*Башыңнан сыйпаганда.*
*Бер җылы сүзе белән*
*Кайгыңны таратканда.*

*Хатын-кызның күзе нурлы*
*Яратып караганда.*
*Җылы карашлары белән*
*Дөньяңны яктыртканда.*

**/Рәсми хәбәрләр/**

### III чирек нәтиҗәләре

22 нче март көнне уку елының III чирере тәмамланды. 41 укучының 35 енә чирек билгеләре чыгарылды. Шулай теп, чирек нәтиҗәләре буенча белем сыйфаты 67% тәшкил итте. I сыйныфтан **Гафиятуллина Руфинә,** III сыйныфтан **Закиров Инсаф, Камалов Илнур,** IV сыйныфтан **Нурматова Асия, Хусенов Дима**, VI сыйныфтан **Закирова Ләйсән**, VII сыйныфтан **Гафиятуллин Фаил** III чирекне гел “5” ле билгеләренә тәмамладылар.

Язгы каникуллар 22 нче марттан башланды. IV чирек 1 нче апрельдән башланачак.

***Илдар Сафиуллин, укыту эшләре буенча директор урынбасары***



*/Безнең бәйрәмнәр/*

## *“Без бергә” дә бергә без*!

Сәнгать белән кызыксынучы балаларга сәләтләрен үстерү, үзләрен сынап карау өчен нинди генә бәйгеләр юк! 5 нче мартта Аксубай районы мәдәният йортында “Без бергә!” бәйгесенең халык иҗаты республика балалар сәнгать фестиваленең муниципаль туры үтте. Бәйгедә мәктәп һәм өстәмә белем бирү учреждениеләре укучылары катнашты. Фестивальнең номинацияләре дә күптөрле: вокал (соло), халык ансамбле, хореография, инструменталь ансамбль, нәфис сүз, иҗади гаилә һәм театр.



Безнең мәктәп укучылары да әлегә фестивальдә ел саен уңышлы чыгыш ясыйлар. Бәйге тәгәлләнгәч жюри алдынгы урыннарны билгеләде. Безнең **“Бәхетле балачак”** дип исемләнгән мәктәп театры, мондый зур ярышта тәүге тапкыр катнашты. Шуңа да карамастан, артистларыбыз**Гафиятуллина Руфинә, Сафиуллина Гөлсем, Нурматова Асия, Сафеева Настя, Залиева Василәь, Хабибрахманова Хәнифәләр** сәхнәдә сынатмадылар. Алар сәхнәләштергән “Өч кыз” әкияте II урынны яулады.

**“Төрле юнәлештәге иҗат әсәрләрен сәхнәләштереп күрсәтү”** номинациясендә **Нурматова Асия, Закирова Ләйсән, Насырова Кәүсәр, Сафеева, Зәлиева Василәь, Вәлиева Мәрьям, Вәлиев Ибраһим** кергән иҗади төркем “Кыйсаи Йосыф” кыйссасын көйләп башкардылар. Мөнәҗәт төкеме яңа составта зур сәхнәдә беренче тапкыр гына чыгыш ясавына карамастан, III урынга лаек булды.



"Иҗади гаилә" номинациясендә III нче сыйныф укучысы **Закиров Инсаф**, бабасы **Шакиров Азат** абый белән җыр башкарып, III урынны алдылар. Ә кул эшләре күргәзмәсендә IX сыйныф укучысы **Хәйруллин Айназның** шамаилләре лаеклы I урынны алды. Айназның бу эшенә тиңнәр булмады. V нче сыйныф укучылары **Донсков Артур** һәм **Җамалетдинов Зөлфәт** татарча биеп күрсәтте ләр. Бергәләшеп әзерләгән, күп көч куйган чараның нәтиҗәсе дә куңелле. Укучыларга, әти-әниләргә һәм балаларны әзерләгән укытучыларга олы рәхмәтебезне белдерәбез!

*Самат Гафиятуллин, X сыйныф укучысы*

## *8нче Март – кызлар, әниләр бәйрәме*.




6 нчы март көнне башлангыч сыйныф укучыларының Халыкара хатын-кызлар көненә багышланган бәйрәм кичәсе булып узды. Укучылар әниләренә булган теләкләрен шигырьләргә, җырларга салып җиткерделәр. Алдан үз куллары белән әзерләгән открыткаларын тапшырдылар. Балаларның чын күңелдән ясаган кул эшләре әниләренә зур бүләк булды.

Бәйрәм барышында әниләребезне дә уйнатып, күңелләрен күтәреп алдык. Алар үзләренең сәләтләрен "Көйне бел" дип аталган бәйгедә күрсәттеләр. Көйләрне белеп кенә калмыйча, рәхәтләнеп җырлап та күрсәттеләр. Әниләр эштә дә, сәхнәдә дә сынатмыйлар шул. Бәйрәмнең иң күркәм, берләштерә, серләштерә торган тәмле өлеше дә – бергәләп чәй эчү дә булды. Чәй артында әниләре белән балалары тагын да якынаюга бер сәбәп булды. Әти-әниләр белән бергә уздырган чаралар балалар күңеле өчен дә, сыйныф җитәкчеләре өчен дә уңышлы чара булып торалар.

7 март көнне бу бәйрәм югары сыйныф кызлары өчен уздырылды. Кызлар “Яз” һәм “Кояш”командаларына бүленеп ярыштылар. Бәйгедә шактый гына биремнәр кертелгән иде. Монда табышмакларга җавап табу, мода күрсәтү, мәкаль буенча рәсем ясау, яулык бәйләү, тизлеккә су эчү кебек бәйгеләр булды. Кызлар алдан әзерләнгән сынауларга да, ярыш барышындагы биремнәргә дә тырышып җавап бирделәр.

Динә апа ярышның ахырында командалар өчен квест уздырды. Бу кызыклы уенда алар мәктәптә яшерелгән “байлык”ны эзләделәр. Шартлы биремнәрдән торган эшнең нәтиҗәсен бераз көткән арада тамашачылар өчен дә төрле уеннар уздырылды. Монда логик фикерне эшкә җигү өчен биремнәр, кызыклы фактларга караган сораулар бирелде. Укучылар да, укытучылар да катнашкан бу уенда баллар куелды. Күп бал җыючылар тәмле күчтәнәчләр белән бүләкләнде. Ә командаларның ярышына нәтиҗә ясаганнан соң, бернечә очко аерма белән, “Кояш” командасы җиңү яулады.

Мондый бәйрәмнәр бездә бик җанлы итеп уза. Һәркемнең житезлеге, уңганлыгы, осталыгы сынала. Кызларга да бик күп эшләрнең тәртибен дә белергә, телгә дә оста булырга туры килә мондый бәйгеләрдә.

*Ләйсән Закирова, VI сыйныф укучысы*



*/Мәктәп тормышы/*

## *Укучылар советы эшчәнлеге*

5март көнне мәктәптә укучылар советы җыелышы узды. Монда тәрбия буенча директор киңәшчесе Динә апа балалар белән мәктәп тормышына кертергә теләгән үзгәреш турында фикер алышты. Укучылар волейбол түгәрәге оештырырга тәкъдим иттеләр. Бу максатны тормышка ашыру бурычларын да барладылар. Мәктәптә рәсми эшләүче түгәрәкләр саны чикләнгәнлектән, волейбол түгәрәге мәктәп житәкчелеге, укучылар һәм эти-әниләрнең үзара килешүе нигезендә оештырылачак.

## *“Кайда үлем саталар, хәбәр ит” акциясе*



Бу акция мәктәптә 15нче – 26нчы март көннәрендә уздырылды.Чара кысаларында укучылар өчен профилактик әңгәмәләр үткәрелде. Балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлек белгечләре, сыйныф җитәкчеләре балаларга тәмәке тартуның, наркотик һәм психоактив матдәләрнең зыяны турында сөйлиләр. Аларга административ хокук бозуларны һәм җинаятьләрне булдырмау буенча лекцияләр укылды. Чара катнаш дәресләр рәвешендә – мәгълумат бирү, ә соңыннан материалны дискуссияләр һәм түгәрәк өстәлләр рәвешендә ныгыту өчен уен формасында узды. Үз сәламәтлегеңне саклау, начар гадәтләрне читләп үтү турында үтемле итеп аңлатылды.

*Әхсәнова Мәдинә, VI сыйныф укучысы*

*/Безнең уңышлар/*

## *Иҗади бәйгеләрнең нәтиҗәләре*




27 март – бөтендөнья театр көне. 1961 нче елдан башлап барлык театр куючылар бу көнне үзләренең һөнәри бәйрәмнәрен билгеләп үтәләр. Безнең мәктәптә,бу уку елы башыннан алып, башлангыч сыйныф укытучысы **Хәбибрахманова Сафия апа** җитәкчелегендә театр түгәрәге эшли башлады. Анда балалар үзләрен сәхнәдә, тамашачы алдында тотарга, рольләр уйнарга, сөйләм сәләтен, сәхнә культурасын камилләштерергә өйрәнә. Ә 13 мартта безнең түгәрәк **“Бөтен дөнья – театр”** район театр иҗаты конкурсында катнашты. Алар «Туган телдә иң яхшы театраль постановка» номинациясендә икенче урын алдылар. Беренче тапкыр сәхнәдә сыналган укучыларыбызга киләчәктә дә уңышлар телибез.

------------------------------------------------------------




15 март көнне Аксубайның Беренче мәктәбендә **«Тере классика»** Бөтенроссия укучылар конкурсының муниципаль этабы узды. Бу чараның максаты – укучыларда китап укуга мәхәббәт тәрбияләү, мәктәптә өйрәнелмәгән язучыларның иҗаты белән дә танышу.

Конкурста катнашучыларга прозада танылган әдәби әсәрләрдән өзекләрне ятлап, әсәрнең тәэсир көчен тамашачыга җиткерү бурычы йөкләнгән иде. Катнашучылар бик тырышып әзерләнгәнлектән, чара матур узды. Конкуста VIсыйныф укучысы **Насыйрова Кәүсәр** һәм XI сыйныф укучысы **Шичкина Карина** үзләренең осталыкларын мәктәп программасына кертелмәгән әсәрләр аша күрсәттеләр. Насыйрова Кәүсәр призер дипломы, ә Шичкина Карина катнашучы дипломы белән бүләкләнде. Бу чараны оештыручылар безнең укучыларны рус телендә акцентсыз сөйләүләре өчен дә мактадылар.

------------------------------------------------------------------------------------------------------------

Бу чирек ахырында район мәгариф бүлеге тарафыннан **“Эзләнәбез һәм проектлыйбыз”** дигән конкурс үткәрелде. Чараның максаты – районның талантлы балаларын барлау. Безнең мәктәптәнVII сыйныф укучысы **Гафиятуллин Фаил** математика фәне буенча II урынга лаек булды. Укытучысы **Зарипов Фәнил абый** җитәкчелегендә ул элеккеге математика дәреслекләре турында эш әзерләгән иде.

Шулай ук кече яшьтәге мәктәп балалары өчен **“Дөнья – балалар күзлегеннән”** дип аталган конкуста “Күп балалы гаиләдә хезмәт бүленеше” дип аталган эше белән I сыйныф укучысы **Хәбибрахманова Асия** III урынны алды. Укытучысы – **Хәбибрахманова Сафия апа**.

*Зәйнәп Нурматова, X сыйныф укучысы*